# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«02» 04 2021 ел Яр Чаллы № 1031

ТР Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылы Восточная микрорайонында Полевая, Подгорная, Вишневая, Поселковая, Строительная, Советская, Студенческая, Корабельная, Радужная, Парковая, Тенистая, Садовая, Луговая, Нижняя урамнары буенча торак пунктны газлаштыру өчен территорияне планлаштыру проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге нигезендә, Кече Шилнә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, район уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылы Восточная микрорайонында Полевая, Подгорная, Вишневая, Поселковая, Строительная, Советская, Студенческая, Корабельная, Радужная, Парковая, Тенистая, Садовая, Луговая, Нижняя урамнары буенча торак пунктны газлаштыру өчен территорияне планлаштыру проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, техник регламентлар таләпләре нигезендә алып барырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ • р 06-88/09 • ИНН 1639031830